Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге
Колай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

29 октябрь, 2023 ел № 5

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегенең Колай торак пунктында 2022 елның 29 октябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 819 (сигез йөз унтугыз).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 426 (дүрт йөз егерме алты).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 391 (өч йөз туксан бер).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 35 (утыз биш).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2024 елда Колай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, сугыш хәрәкәтләре ветераннарын, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, көндезге уку формасы студентларын һәм мәктәп укучыларын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- янгын гидрантларын урнаштыру;
- Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга куелган һәйкәлне ремонтлау;
- авыл эчендәге юлларны ремонтлау» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Колай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Колай авыл җирлеге башлыгы Поповская Н.В. Поповская